ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨЧКҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2024 елның «19» ноябреннән 126 номерлы

«Туристлык салымы турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге нигезендә, Өчкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге Советы карар кабул итте::

1. 2025 елның 01 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге территориясендә туристлык салымы билгеләргә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә: 2025 елда – 1 процент, 2026 елда – 2 процент, 2027 елда – 3 процент, 2028 елда - 4 процент, 2029 елдан башлап-5 процент.

3. Салым түләү тәртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендә билгеләргә.

4. Вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе салым базасына кертелми торган физик затлар категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белән билгеләнгән.

5.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге территориясендә туристлык салымын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә исәпләнгән туристлык салымы суммасы 100 сумның тапкырлавы һәм яшәү тәүлеге саны буларак исәпләнгән минималь туристлык салымы суммасыннан кимрәк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күләмендә билгеләнә.